# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы

**Урсай авылы** **№129** **28 январь 2018 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 15 октябрь 41нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарга үзгзрешләр кертү турында (2013 елның 11 ноябрь 60-А номерлы, 2014 елның 18февраль 85нче номерлы, 2014 елның 18 август 102нче номерлы, 2017 елның 4 сентябрь 67нче номерлы карарлар редакциясендә)

2017 елның 29 декабрендәге 463 номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Урсай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2012 елның 15 октябрь 41нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарга үзгзрешләр кертү турында (2013 елның 11 ноябрь 60-А номерлы, 2014 елның 18февраль 85нче номерлы, 2014 елның 18 август 102нче номерлы, 2017 елның 4 сентябрь 67нче номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны карап тотуга юнәлтелгән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге.

Төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пунктын өстәргә:

«2.10.3.1.Йорт тамгаларындагы , тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү белән урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш , дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Председатель И.А.Абдуллин